ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 19 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^3$ пункт өстәргә:
«$7^3$) порт гидротехник корылмаларны (шул исәптән причалларны), йөк төяү комплексларын һәм елга портында урнашкан башка мөлкәтне (алга таба – елга порты объектлары) хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгели;»;

2) 8 статьяның 2 өлешенә:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа унбишенче һәм уналтынчы абзацлар өстәргә:
«Елга порты объекты хосусыйлаштырылган очракта, Россия Федерациясе Эчке су транспорты кодексының 53 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә эчке су транспорты инфраструктурасы объектлары буларак файдаланылмый торган объектларга кертелгән елга порты объектыннан (алга таба – эчке су транспорты инфраструктурасы объекты буларак файдаланылмый торган елга порты объекты) тыш, елга порты объектын аннан «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның $30^3$ статьясындагы 1 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән

максатларга туры китереп файдалану йөкләмәсе белән чикләп тору хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарга мөһим шарт буларак кертелергә тиеш.

Эчке су транспорты инфраструктурасы объектлары буларак файдаланылмый торган елга порты объектлары «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм ысуллар белән, әлеге Федераль законның $30^3$ статьясында билгеләнгән чикләп торуларны исәпкә алмыйча, хосусыйлаштырылырга мөмкин.»;

б) унбишенче һәм уналтынчы абзацларны тиешенчә унҗиденче һәм унсигезенче абзацлар дип санарга;

3) 10 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацта «һәм мондый челтәрләр объектларын» сүзләреннән соң «, канәгатьләнмәслек торышта булган елга порты объектларын» сүзләрен өстәргә;

б) алтынча абзацта «һәм мондый челтәрләр объектларына» сүзләреннән соң «, канәгатьләнмәслек торышта булган елга порты объектларына» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 26 маеннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 29 апрель
№ 24-ТРЗ